Югары Чура авыл жирлеге Советы

КАРАР

«27» февраль 2023 ел №3

Югары Чура авыл жирлеге Советының 2018 елның 27 апрелендэге 8 номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл жирлегендэ муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында»2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Югары Чура авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Югары Чура авыл җирлеге Советының 2018 елның 27 апрелендәге 8 номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә (2018 елның 7 ноябрендәге 25 номерлы, 2019 елның 17 маендагы 11 номерлы, 2020 елның 20 мартындагы 7 номерлы, 2021 елның 25 мартындагы 7 номерлы, 2022 елның 15 июнендәге 12 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 8 бүлекнең 1 пунктына түбәндәге эчтәлектәге 12 пунктчаны өстәргә:

«12) алар тарафыннан чит ил агенты статусын алу.»;

1) 15 бүлекнең 1 пунктына түбәндәге эчтәлектәге 5 пунктчаны өстәргә:

«5) муниципаль хезмәткәр тарафыннан чит ил агенты статусын алу.».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында», Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://kukmor.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлеге территориясендәге мәгълүмат стендларында бастырырга.

Югары Чура башлыгы В.Н.Андреев